**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы**
**Карар**

**№ 145** **от 23.09.2024 года**

**2022 елның 25 октябреннән 78 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Дүрт-Мунча авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елның 25 октябреннән 78 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.6.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.4. Планнан тыш күчмә тикшерү бары тик прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелә ала, моңа 248-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 1 өлешенең 3 - 6 пунктларына, 57 статьясындагы 3 өлешенә 12 һәм 12.1 өлешләренә туры китереп уздырылган очраклар керми.»;

1.2. 4.7.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.7.10. Рейд тикшерүе, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3 - 6 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә аны үткәрү очракларыннан тыш, прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин.»;

1.3. 4.9.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9.5. Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктындагы 2 пунктчасында каралган карар кабул ителә алмый.».

2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) да, җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә әлеге карарны бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Дүрт-Мунча авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Т. Ситдыйков.